СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә
авылы, Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Советы**

## КАРАРЫ

**« 30 » сентябрь 2022 ел** **№ 60**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләме һәм түләү шартлары турында» Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 маендагы 104 номерлы карарына (29.12.2021 №42 үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыклары, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарлары, депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, урынбасарлары, аудиторларының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге Уставы нигезендә, Иске Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләме һәм түләү шартлары турында» Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 маендагы 104 номерлы карарына (29.12.2021 №42 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәт хакы турында нигезләмәнең 3 нче абзацын (1 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затның хезмәт хакы акчалата бүләкләү рәвешендә башкарыла.

| Вазыйфа исеме | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Иске Кырлай авыл жирлеге башлыгы | 17944 |

2) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге жирле үзидарә органнарында һәм муниципаль учреждениеләрендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт хакы турында нигезләмәнең 12 абзацында (2 нче кушымта) «11 498 сум» сүзләрен «11 958 сум» сүзләренә алмаштырырга.

3) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл жирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт хакы турында нигезләмәнең 3 абзацын (4 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Баш хисапчының вазыйфаи оклады түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары халык саны белән: |
|---|---|
| | 3,5 мең кешегә кадәр |
| Баш хисапчы | 19700 сум |

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- Муниципаль вазыйфаны даими рәвештә биләүче затларның хезмәт хакы турында нигезләмәнең 1 нче кушымтасындагы үзгәреш кабул ителгән көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл жирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт хакы турында нигезләмәнең 2 нче кушымтасындагы үзгәреш кабул ителгән көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл жирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт хакы турында нигезләмәнең 4 нче кушымтасындагы үзгәреш кабул ителгән көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында җирлекләр бүлегенә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин

СОВЕТ СТАРОЖЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ